**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Россия Федерациясенең ау һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы җитәкчесенә квалификация таләпләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең ау һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы җитәкчесенә квалификация таләпләрен камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының « Россия Федерациясенең ау һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы җитәкчесенә квалификация таләпләре турында» 2011 елның 24 сентябрендәге ПУ-588 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясенең ау һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы җитәкчесенә квалификация таләпләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «а» һәм «б» пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) вәкаләтле орган эшчәнлегенең тиешле юнәлешләренә, бурычларына һәм функцияләренә туры килүче белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре буенча белгеч, магистратура дәрәҗәсеннән түбән булмаган югары белем;

б) кимендә алты ел Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте (башка төр дәүләт хезмәте) стажы яисә белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча кимендә җиде ел эш стажы;»;

б) «г» пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) түбәндәге һөнәри күнекмәләре булу: норматив хокукый актларны гамәлдә куллану, проектлар эшләү һәм аларга идарә итү, идарәчел карарларны оператив рәвештә кабул итү һәм гамәлгә ашыру, бурычлар үтәүне оештыру һәм тәэмин итү, эшне квалификацияле планлаштыру, эшлекле сөйләшүләр алып бару, халык алдында чыгыш ясау, анализлау һәм фаразлау, хезмәттәшләре фикерен дөрес итеп исәпкә алу, вәкаләтләрне үз кул астында эшләүчеләргә тапшыру, дәүләт органнары белән нәтиҗәле хезмәттәшлек эшен оештыру, эш вакытын нәтиҗәле планлаштыру, кирәкле

программа тәэминатын үзләштерү, үз квалификациясен системалы күтәрү, коллегалары белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итү, мәгълүматны системалаштыру, хезмәт документлары белән эшләү, яңа вазгыятькә җайлашу һәм куелган бурычларны хәл итүгә яңача якын килү, шәхси конфликтларны булдырмау буенча үз буйсынуындагы граждан хезмәткәрләре белән квалификацияле эшләү.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 18 апрель
№ ПУ-316